**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Чарлы авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**07 ноябрь, 2025 ел** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге Татар Толлысы авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 26 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Татар Толлысы авылы, Яшел урамы, 41 адресында урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. 2025 елның 26 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Татар Толлысы авылы, Яшел урамы, 41 адресында урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Чарлы авыл җирлеге Татар Толлысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә житкән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Чарлы авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чарлы авыл җирлеге башлыгы Э.Н.Козлов